МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.12.2018 г. Казань № под-1945/18

«Иннополис мәктәбе» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесенең мәктәпкәчә төркемнәрендә ата-аналар түләве күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясындагы 2 өлеше һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2013 елның 30 декабрендәге 1096 номерлы карары нигезендә б о е р а м:

1. 2019 елга мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы «Иннополис мәктәбе» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесенең мәктәпкәчә белем бирү юнәлешендәге мәктәпкәчә төркемнәрдә баланы карап торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең беркетелгән күләмен расларга.

2. «Иннополис мәктәбе» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесенең мәктәпкәчә төркемнәрендә ата-аналар түләве күләмен раслау турында» Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2018 елның 19 гыйнварындагы 102/18 номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Мәктәпкәчә белем бирү бүлегенә (Э.А. Измайлова) эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә, боерык кабул ителгән көннән алып, аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. Әлеге боерык 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары И.Г. Хәдиуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр Р.Т.Бороһанов

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
боерыгы белән расланды
24.12.2018 № под-1945/18

**2019 ЕЛГА МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ ПРОГРАММАСЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ «ИННОПОЛИС МӘКТӘБЕ» ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕНЕҢ ГОМУМИ ҮСЕШТӘГЕ МӘКТӘПКӘЧӘ ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БАЛАНЫ КАРАГАН ҺӘМ КАРАГАН ӨЧЕН**
**АТА-АНАЛАР ТҮЛӘВЕ КҮЛӘМЕ**

| Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының атнага эш көннәре саны | Мәгариф оешмасының мәктәпкәчә төркемнәрнең эш сәгатьләре саны | Бала саны | Бер тәрбияләнүче өчен ата-аналар түләве күләме, аена сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барлыгы | | | шул исәптән азык-төлек продуктларының бәясе | | |
| | | | 2 айдан 1 елга кадәр | 1 елдан 3 елга кадәр | 3 елдан 7 елга кадәр | 2 айдан 1 елга кадәр | 1 елдан 3 елга кадәр | 3 елдан 7 елга кадәр |
| 5 эш көне | 10,5 | өчтән ким | 5714 | 3252 | 3251 | 1165 | 448 | 565 |
| | | өч һәм аннан артык | 2857 | 1626 | 1626 | 582 | 224 | 282 |